| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.08.2026 Балык Бистәсе штп. №221пи

2027 елга Татарстан Республикасында авыл территорияләрендә торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясен раслау турында

Россия Федерациясенең “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен төзү, раслау, үзгәртү һәм авыл территорияләрендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү Тәртибенең 19 пункты һәм Гражданнар исемлекләрен төзү, раслау һәм үзгәртү тәртибенең 21 пункты нигезендә – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында “Авыл территорияләрен комплекслы үстерү” Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында” 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы карары белән расланган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак алучылар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2027 елга Татарстан Республикасында авыл территорияләрендәге гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен раслау турында" 2026 елның 8 июлендәге 852 номерлы карарын игътибарга алып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2027 елга Республикада авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясен расларга:

Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту чаралары кысаларында торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгару өчен 37 614,0 сум күләмендә;

торак урынны наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидия күләмен исәпләп чыгару өчен 74 532,0 сум күләмендә.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы

буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Д.Н. Ризаев